ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

# РӘХМӘТ СҮЗЕ

*Хөрмәтле Илнат Илшат улы Хәсәнов!*

*Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Безнең бай тарихыбыз, мәдәниятебез, мәгарифебез, батыр, эшчән халкыбыз бар. Авыллар тарихы – халкыбыз тарихының аерылгысыз бер өлеше. Аларны өйрәнү, үзең яшәгән төбәк белән горурлану хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы. Халкыбызның рухи мирасын, аның тарихын өйрәнүдә балаларга чын мәгънәсендә әхлак тәрбиясе бирүдә туган як музее эшчәнлеге әйтеп бетергесез әһәмияткә ия.*

*Туган як тарихын барлау, туплау эшендә активлык күрсәтеп, Байкиев К.С. исемендәге Икшермә кадет интернат-мәктәбендә “Тарихи-патриотик” музей булдыруда ярдәм иткүегез өчен Сезгә тирән рәхмәтемне белдерәм.*

*Алдагы көннәрегездә сәламәтлек, озын гомер, гаилә бәхете, куйган хезмәтегезнең, кылган яхшылыкларыгызның бәрәкәтен күреп яшәвегезне телим.*



*Саба муниципаль районы башлыгы* — Р.Н.МИННИХАНОВ

*май, 2021 ел*